# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Яшьләр турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья.** «Яшьләр турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, №10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 15 яшьтән яшьрәк затларны эшкә алу рөхсәт ителми.

Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарны сәламәтлеккә зыян китерми һәм уку процессын бозмый торган җиңел хезмәт башкару өчен эшкә алу, аларга 14 яшь тулгач, ата-аналарының берсенең яисә аларны алмаштыручы затның ризалыгы белән, укудан буш вакытта рөхсәт ителә.».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М. Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1146